Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының чираттан тыш утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 июнь, 2020 № 270

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, 2020 елның 15 маендагы гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА